КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 945

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 декабрь, 783 нче карары белән расланган «Хокук тәртибен ныгытудагы казанышлар өчен» күкрәк билгесе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хокук тәртибен ныгытудагы казанышлар өчен» күкрәк билгесе турында» 2007 ел, 29 декабрь, 783 нче карары белән расланган «Хокук тәртибен ныгытудагы казанышлар өчен» күкрәк билгесе хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренең федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы прокуроры, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары җитәкчеләре.» сүзләрен өстәргә;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Хокук тәртибен ныгытудагы казанышлар өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләү турында хезмәткәрнең шәхси эшенә һәм хезмәт кенәгәсенә тиешле язу языла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин